ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31 июля 2015 г. № 4353

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә
ашыруның административ
регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2013 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 31 октябрендәге 27/14 номерлы Карары, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты каршында муниципаль торак контроле буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 27 февралендәге 1167 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге

территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын тиешле мәгълүмат системаларында урнаштыру һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру өчен Яр Чаллы шәһәренең «Мәгълүмати технологияләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесенә җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Н.Г. Мәһдиев

Башкарма комитетның
2015 елның 31 июлендәге
4353 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның
административ регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру» административ регламенты (алга таба – Административ регламент) муниципаль торак контролен (алга таба – муниципаль контроль) гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәгәндә административ процедуралар һәм административ гамәлләрнең срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

2. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы орган булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының составы Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты каршында муниципаль торак контроле буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 27 февралендәге 1167 номерлы карары белән расланган Муниципаль контроль комиссиясе йөзендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – муниципаль торак контроле органы) тора.

3. Муниципаль контроль түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе («Российская газета», №7, 21.01.2009; «РФ Законнар җыентыгы», 26.01.2009, №4, ст.445; «Парламентская газета», N4, 23-29.01.2009);

- Россия Федерациясе Торак кодексы, 29.12.2004, №188-ФЗ («РФ Законнар җыентыгы», 03.01.2005, №1 (1 өлеш), ст. 14; «Российская газета», 12.01.2005, №1; «Парламентская газета», 15.01.2005, №7-8)

- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы 30.12.2001, №195-ФЗ («Российская газета», 31.12.2001, №256; «Парламентская газета», №2-5, 05.01.2002; «РФ Законнар җыентыгы», 07.01.2002, №1 (1 өлеш), ст. 1);

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон («РФ Законнар җыентыгы», 06.10.2003, №40, ст. 3822; «Парламентская газета», №186, 08.10.2003; «Российская газета», №202, 08.10.2003);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон («Российская газета», №266, 30.12.2008; «РФ Законнар җыентыгы», 29.12.2008, №52 (1 өлеш), ст. 6249; «Парламентская газета», № 90, 31.12.2008);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары («РФ Законнар җыентыгы», 12.07.2010, №28, ст. 3706);

- Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы Приказы («Российская газета», №85, 14.05.2009);

- Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 24.01.2013 ел, № 6 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе һәм муниципаль торак контроле органнарының үзара хезмәттәшлегенең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 24 гыйнварындагы 6 номерлы Приказы;

- «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы;

- Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 30 октябрендәге 27/14 номерлы Карары;

- Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты каршында муниципаль торак контроле буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 27 февралендәге 1167 номерлы карары һәм башка муниципаль хокукый актлар.

4. Муниципаль торак контроленең предметы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар белән муниципаль торак фондына карата билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) үтәү тора.

5. Муниципаль контроль бер үк вакытта муниципаль торак инспекторлары да булган комиссия әгъзалары тарафыннан гамәлгә ашырыла (алга таба – вазыйфаи затлар).

6. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда вазыйфаи затлар түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәлилләнгән язмача запрослар нигезендә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, физик затлардан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны соратырга һәм алырга;

2) хезмәткәр таныклыгын һәм муниципаль торак контроле органы җитәкчесенең тикшерү билгеләү турында Боерыгы күчермәсен күрсәтеп, территориягә һәм анда урнашкан күпфатирлы йортларга, наемга алынган социаль файдаланудагы йортларга, күпфатирлы йортлардагы гомуми файдаланудагы бүлмәләргә тоткарлыксыз керергә; күпфатирлы йортлардагы торак милекчеләренең ризалыгы буенча торак бүлмәләргә керергә һәм аларны тикшерергә; тикшерүләр,

сынаулар, тикшеренүләр, экспертизалар һәм контроль буенча башка чаралар үткәрергә, наемга алынган социаль файдаланудагы йортларда торак бүлмәләрне наемга бирүчеләр тарафыннан шундый йортларны наемга бирүчеләргә һәм наемга алучыларга, социаль файдаланудагы торак фондының торак бүлмәләрен наемга алу килешүләре һәм торак бүлмәләрне наемга алу килешүләре бәяләмәсенә һәм үтәлешенә карата куелган мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен, Россия Федерациясе Торак кодексының 91.18 статьясының 2 өлеше нигезендә каралган затлар тарафыннан наемга алынган социаль файдаланудагы йортларны муниципаль реестрда исәпкә алу өчен кирәкле мәгълүматларны раслаучы документларны тапшыруга карата куелган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

3) мәҗбүри таләпләрне бозуны туктату, ачыкланган кимчелекләрне бетерү, мәҗбүри таләпләрне үтәүне тәэмин итү буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмә бирергә;

4) гамәлдәге законнар нигезендә җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату мәсьәләләрен хәл итү өчен, мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрергә;

5) гамәлдәге законнар нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуларны булдырмау буенча чаралар күрергә.

7. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда вазыйфаи затларның бурычлары:

1) Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри таләпләрне һәм муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм булдырмау буенча вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулысынча үтәү;

2) Россия Федерациясе законнарын, тикшерелә торган затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;

3) тикшерүне Башкарма комитет Җитәкчесе боерыгы нигезендә үткәрү;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәгән вакытта, хезмәт таныклыгын, Башкарма комитет Җитәкчесе боерыгын күрсәтеп кенә үткәрү.

5) тикшерүче затка, аның законлы вәкиленә тикшерү үткәргәндә комачаулык итмәү һәм тикшерү предметына караган сорауларга аңлатмалар бирү;

6) тикшерүче затка, аның законлы вәкиленә тикшерү үткәргәндә тикшерү предметына караган мәгълүматлар һәм документлар бирү;

7) тикшерүче затны, аның законлы вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру;

8) ачыкланган кимчелек фактлары буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә, күрсәтелгән чараларның кимчелекләрнең авырлык дәрәҗәсенә туры килүен, аларның кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт куркынычсызлыгына зарар килү, табигый һәм техноген характерындагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның потенциал куркынычын исәпкә алу, шулай ук тикшерүче затның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймау;

9) тикшерүче зат тарафыннан шикаять бирелгәндә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә үз гамәлләренең нигезлелеген исбатлау;

10) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын үтәү;

11) тикшерүче заттан, аның законлы вәкиленнән Россия Федерациясе законнарында каралмаган документларны һәм башка мәгълүматларны бирүне таләп

итмәү;

12) тикшерү башланыр алдыннан тикшерүче затның, аның вәкаләтле вәкиленең үтенече буенча тикшерү шуның нигезендә үткәрелә торган административ регламентның нигезләмәләре белән таныштыру;

13) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль контроль органы алган дәүләт, коммерция, хезмәт, закон белән саклана торган башка серне булган мәгълүматны, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, таратмаска;

14) әлеге административ регламент нигезендә муниципаль контрольне үтәргә.

8. Муниципаль контрольне үтәгәндә вазыйфаи затлар:

- билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары белән хезмәттәшлек итәләр;

- гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә карап тикшерә.

9. Муниципаль контроль буенча чаралар гамәлгә ашырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары:

10. Тикшерү үткәргәндә чаралар гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль субъектының хокуклары:

1) Муниципаль контрольне үтәү тәртибе турында тулы һәм дөрес мәгълүмат алу;

2) үз хокукларын һәм бурычларын мөстәкыйль рәвештә яисә законлы вәкил аша гамәлгә ашыру;

3) тикшерү уздырганда турыдан-туры катнашу, тикшерү предметына караган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирү;

4) муниципаль контроль органыннан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына караган мәгълүматны алу;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышу һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышу, алар белән килешмәү, шулай ук муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән танышу;

6) муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының әлеге административ регламентта билгеләнгән тәртиптә һәм (яисә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә тикшерелә торган затның законлы хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү.

11. Тикшерү үткәргәндә чаралар гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль субъектының бурычлары:

- муниципаль контроль органына (аның вазыйфаи затларына) нигезләнгән таләбе буенча үзенә йөкләнгән вәкаләтләр нигезендә муниципаль контроль органына тиешле документлар, аңлатмалар, язма һәм телдән мәгълүмат (шул исәптән коммерция, хезмәт, закон тарафыннан саклана торган башка сер булган мәгълүмат), шул исәптән актлар, шартнамәләр, белешмәләр, цифрлы язма рәвешендә яисә электрон чыганакларда язма рәвешендә башкарылган башка документларны һәм материалларны да кертеп, тапшыру.

12. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның ахыргы нәтиҗәсе булып тора:

1) «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында «Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы РФ Икътисадый үсеш министрлыгы Приказы белән расланган форма буенча тикшерү актларын төзү;

2) кимчелек ачыклаганда, мәҗбүри таләпләрне бозуларны туктату турында һәм аларны бетерү турында, аларны үтәү срокларын күрсәтеп, күрсәтмәләр бирү;

3) ачыкланган кимчелекләрне бетерүне, аларны кисәтү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүне булдырмау, шулай ук ачыкланган кимчелекләргә юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү, шул исәптән:

а) Татарстан Республикасы Дәүләт торак күзәтчелеге органына, аның компетенциясе нигезендә, административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле, административ хокук бозу турында эш кузгату мәсьәләсен хәл итү өчен, материаллар җибәрү;

б) җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату мәсьәләләрен хәл итү өчен, мәҗбүри таләпләрне бозу белән бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрү.

## 2 бүлек. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга таләпләр

13. Муниципаль контроль органының урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, почта адреслары, электрон почта адреслары турында мәгълүмат:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының урнашу урыны: 423800, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 414, 415 кабинетлар.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының эш графигы:

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе – җомга | 8.00 - 1 7.00 |
| Төшке аш вакыты | 12.00 - 13.00 |
| Шимбә, якшәмбе | ял көне |

3) белешмә телефоннары:

- кабул итү бүлмәсе: (8552) 30-55-57;
- факс 30-59-52;

14. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма органының рәсми сайт һәм электрон почта адреслары:

1) муниципаль контроль органының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты: www.nabchelny.ru (алга таба – рәсми сайт);

2) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә мөрәҗәгать итү өчен электрон почта адресы: Kr415@mail.ru (алга таба – электрон почта адресы).

15. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат түбәндәге ысуллар белән бирелә:

1) телефон элемтәсе чараларын кулланып;

2) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: www.nabchelny.ru;

3) электрон почта чаралары буенча Kr415@mail.ru;

4) турыдан-туры шәхси кабул итү кысаларында;

5) язма рәвештә (әлеге административ регламентның 13 пунктында күрсәтелгән почта аша, реквизитлар буенча мөрәҗәгать иткәндә);

16. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибе турында мәгълүмат Башкарма комитет бүлмәләрендәге «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 21 апрелендәге 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар кабул ителә торган мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән муниципаль контроль үткәрү өчен түләү, шул исәптән контроль чаралар үткәрүгә җәлеп ителгән очракта, эксперт һәм эксперт оешмалары хезмәтләре өчен дә алынмый.

17. Һәр тикшерүне (документар яки күчмә) үткәрү вакыты 20 (егерме) эш көненнән дә артмаска тиеш.

18. Кече эшмәкәрлекнең бер субъектына карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен елына 50 сәгатьтән һәм микропредприятиеләр өчен 15 сәгатьтән артмаска тиеш.

19. Күчмә планлы тикшерү үткәрүче муниципаль торак инспекторларының дәлилләнгән тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы тикшеренүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшерүләр үткәрү зарурлыгы белән бәйле аерым очракларда, күчмә тикшерүне үткәрү вакыты Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан 20 (егерме) эш көненнән, кече предприятиеләргә, микропредприятиеләргә карата унбиш сәгатьтән дә артмаска тиеш.

## 3 бүлек. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү бурычлары

20. Муниципаль контроль түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) тикшерүләрне планлаштыру;

2) тикшерү үткәрү турында карар кабул итү һәм аны үткәрүгә әзерлек;

3) документар тикшерү үткәрү;

4) күчмә тикшерү үткәрү;

5) планнан тыш күчмә тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

6) тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә бирү;

7) тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләргә юл куйган юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне җаваплылыкка тарту максатларында тикшерү материалларын тапшыру;

8) тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмәнең үтәлешен тикшерү.

21. Әлеге административ регламентның 20 пунктындагы 6-8 пунктчаларында күрсәтелгән административ процедуралар өстәмә булып тора

һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозулар ачыкланган очракта гамәлгә ашырыла.

22. Муниципаль контрольне башкаруның административ процедураларының (гамәлләрнең) блок-схемасы әлеге административ регламентка 6 нчы кушымтада бирелгән.

23. Комиссия тарафыннан тикшерүләрне планлаштыру ел саен башкарыла.

24. Комиссия планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 июленә кадәр планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын (алга таба – еллык план проекты) эшли һәм аны Комиссия рәисенә килештерүгә җибәрә.

25. Планлы тикшерүне планлы тикшерүләрнең еллык планына кертү өчен нигез булып, социаль файдаланудагы беренче наемга алынучы торак йортның муниципаль реестрында исәпкә куелганнан соң, эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган торак урыннарны наемга алучы тора.

26. Еллык тикшерү планына кертү өчен чикләүләр:

- планлы тикшерү юридик затны яки шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алганнан соң өч елдан да иртәрәк үткәрелмәскә мөмкин;

- бер юридик затка яки шәхси эшмәкәргә карата планлы тикшерү өч елга бер тапкырдан да артык үткәрелмәскә мөмкин (сәламәтлек саклау, мәгариф һәм социаль өлкәдә эшчәнлек алып баручы юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән тыш).

27. Еллык тикшерүләр үткәрү планында түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) планлы тикшерүләргә тиешле юридик затларның исемнәре, фамилияләре, атасының исемнәре, эшчәнлекләре тикшерелергә тиешле шәхси эшмәкәрләрнең исемнәре;

2) һәр планлы тикшерүнең максаты һәм аны үткәрү өчен нигез;

3) һәр планлы тикшерүне үткәрү датасы һәм сроклары;

4) конкрет планлы тикшерүне гамәлгә ашыручы муниципаль контроль органы исеме;

5) планлы тикшерүдә катнашучы дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре.

28. Муниципаль контроль буенча комиссия рәисе планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектының эчтәлеген бәяли һәм кисәтүләр булган очракта, үзгәрешләр кертү вакытын күрсәтеп, еллык тикшерүләр планы проектын эшләп бетерү өчен кире кайтара.

29. Еллык тикшерүләр планы проектының тәкъдим ителгән редакциясенә искәрмәләр һәм тәкъдимнәр булмаган очракта, муниципаль контроль буенча комиссия рәисе аны килештерә һәм планлы тикшерүләр уздыру елыннан алдагы елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча тиешле прокуратура органына җибәрә.

30. Прокуратура органы тарафыннан тәкъдимнәр кертелгән очракта, шул исәптән уртак планлы тикшерүләр үткәрү турында комиссия, муниципаль торак контроле комиссиясе рәисе кушуы буенча, 2 (ике) эш көненнән дә артмаган вакытка, прокуратура органының тиешле тәкъдимнәрен исәпкә алып, планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы проектын эшләп бетерүне тәэмин итә һәм, аны раслау турында карар кабул итү өчен, Башкарма комитет Җитәкчесенә еллык планлы тикшерүләр үткәрү планының эшләп бетерелгән проектын бирә.

31. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планын раслау турындагы карар Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан планлы тикшерүләр үткәрү елыннан

алдагы елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм Башкарма комитет боерыгы белән рәсмиләштерелә.

32. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына үзгәрешләр кертү турында карар Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителә һәм Башкарма комитет боерыгы белән рәсмиләштерелә.

33. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүматлар, алар кертелгәннән соң 10 (ун) көннән дә артмаган вакыт эчендә, комиссия, тиешле прокуратура органына кәгазьдә (күчермәне электрон рәвештә теркәп), заказлы почта аша, җибәрү турында белдерү кәгазе белән яисә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе бүлегендә урнаштырыла. http://nabchelny.ru.

34. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы кәгазьдә (күчермәне электрон рәвештә теркәп) комиссия тарафыннан планлы тикшерүләр уздыру елыннан алдагы елның 1 ноябренә кадәр, прокуратураның тиешле органына заказлы почта аша, җибәрү турында белдерү кәгазе белән яисә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

35. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан расланган планлы тикшерүләр үткәрү планы кызыксынган затларга аны «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе бүлегендә урнаштыру юлы белән җиткерелә. http://nabchelny.ru.

36. Тикшерү үткәрү һәм аны үткәрүгә әзерлек өчен нигез булып тора:

1) планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планына юридик зат, шәхси эшмәкәр турындагы мәгълүматларны кертү;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм (яисә) таләпләрне бозуларны бетерү турында юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы тәмамлану;

3) Башкарма комитетка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, идарәче оешма тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясының 2 өлешендә каралган йөкләмәләрнең бозылу фактлары турында мәгълүматлар, социаль файдаланудагы наемлы йортларда торак урыннарны наемга алучылар тарафыннан мондый йортларда торак урыннарны наемга алучыларга карата мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү;

4) Башкарма комитетка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрдән, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар керү:

- гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян китерү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

- кулланучылар хокукларын бозу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта);

5) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләре нигезендә һәм прокуратура органнарына кергән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе нигезендә чыгарылган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы җитәкчесе приказы (боерыгы).

37. Башкарма комитетның планлы тикшерү үткәрү турындагы боерыгы проекты комиссия тарафыннан планлы тикшерү үткәрү датасына кадәр 30 (утыз) көннән дә соңга калмыйча эшләнә.

38. Тикшерү (планлы, планнан тыш) үткәрү турында карар муниципаль контроль буенча комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә һәм Башкарма комитет боерыгы белән рәсмиләштерелә.

39. Тикшерү (планлы, планнан тыш) үткәрү турында карарда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- муниципаль торак контроле органы исеме;

- муниципаль торак инспекторларының, шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, атасының исеме, вазыйфалары;

- юридик затның исеме яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, тикшерү алып барыла торган юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләр) урнашкан урыны яисә шәхси эшмәкәрләрнең яшәү урыны һәм фактта аларның эшчәнлек алып бару урыны;

- тикшерүнең максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү вакыты;

- тикшерүне үткәрүнең хокукый нигезләре, шул исәптән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләр һәм таләпләр;

- тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле контроль чаралары исемлеге һәм үткәрү сроклары;

- тикшерү үткәрелә торган хокукый актлар, шул исәптән административ регламентлар исемлеге;

- юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен бирелгән документлар исемлеге;

- тикшерүнең башлану һәм тәмамлану даталары;

- муниципаль контроль буенча комиссия рәисе имзасы.

40. Планлы тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшмәкәргә, аны үткәрүгә кадәр, 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча, муниципаль торак контроле буенча комиссия рәисе боерыгы күчермәсен тапшыру турында белдерү кәгазе яки башка мөмкин ысул белән заказлы почта аша хәбәр ителә.

41. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында, уздыру нигезләре административ регламентның әлеге бүлегендәге 36 пунктның 3, 4 пунктчаларында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүләрдән тыш, юридик затка, шәхси эшмәкәргә аны үткәрү башланганчы егерме дүрт сәгать алдан хәбәр ителә.

42. Юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян китерелсә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән

тыш хәлләр килеп чыкса яисә килеп чыгарга мөмкин булса, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә планнан тыш тикшерү үткәрү башлануы турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

43. Әлеге административ регламентның 36 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү прокуратура органнары белән килештермичә һәм тикшерелә торган юридик затка, шәхси эшмәкәргә мондый тикшерү үткәрү турында алдан хәбәр итмичә генә үткәрелә.

44. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән документар тикшерү (планлы, планнан тыш) үткәрү турындагы боерык документар тикшерүне башкару өчен нигез булып тора.

45. Документар тикшерү (планлы, планнан тыш) үткәрү муниципаль торак инспекторы тарафыннан мондый тикшерү үткәрү турында муниципаль торак контроле комиссиясе рәисе боерыгы белән билгеләнгән күрсәтмә белән башкарыла.

46. Документар тикшерү (планлы, планнан тыш) предметы булып юридик зат, шәхси эшмәкәр документларындагы, аларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган, аларның эшчәнлеген тормышка ашырганда файдаланыла торган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешенә, муниципаль контроль органнары күрсәтмәләренең һәм карарларының үтәлешенә бәйле документлар тора.

47. Документар тикшерү (планлы, планнан тыш) комиссия тарафыннан беренче чиратта юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, муниципаль торак контроле комиссиясе рәисе карамагында булган, Яр Чаллы шәһәре хакимиятенең башка органнары һәм структур бүлекчәләре булган документлары, шул исәптән алдагы тикшерүләр актлары һәм юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата гамәлгә ашырылган башка документлар карала.

48. Муниципаль торак контроле комиссиясе рәисе, Башкарма комитетның башка органнары һәм структур бүлекчәләре карамагында булган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шик тудырса, бу мәгълүматлар юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең яисә таләпләрнең үтәлешен бәяләргә мөмкинлек бирми, комиссия юридик зат адресына җибәрә, шәхси эшмәкәрнең адресы документар тикшерү (планлы, планнан тыш) барышында карау өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбе белән дәлилләнгән запрос. Запроска муниципаль торак контроле буенча комиссия рәисе боерыгының билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитет мөһере белән расланган документар тикшерү (планлы, планнан тыш) үткәрү турындагы боерыгының күчермәсе теркәп бирелә.

49. Дәлилләнгән запрос алынганнан соң 10 (ун) эш көне эчендә юридик зат, шәхси эшмәкәр запроста күрсәткән документларны Башкарма комитетка җибәрергә тиеш.

50. Запроста күрсәтелгән документлар шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, җитәкче, юридик затның бүтән вазыйфаи заты имзасы белән (булганда) мөһере белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшмәкәр запроста күрсәтелгән документларны электрон документлар рәвешендә тапшырырга хокуклы.

51. Документар тикшерү (планлы, планнан тыш) барышында юридик зат, шәхси эшмәкәр биргән документларда хаталар һәм (яки) каршылыклар ачыкланган яисә бу документлардагы белешмәләрнең Башкарма комитетта булган документлардагы һәм (яки) муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру барышында алынган белешмәләргә туры килмәве ачыкланган очракта, бу хакта мәгълүмат комиссия тарафыннан юридик затка, шәхси эшмәкәргә 10 (ун) эш көне дәвамында язма рәвештә тиешле аңлатмалар бирү таләбе белән җибәрелә.

52. Муниципаль торак инспекторы җитәкче яки юридик затның башка вазыйфаи заты, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм элек бирелгән документларның дөреслеген раслый торган документларны карарга тиеш. Бирелгән аңлатмаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң аңлатмалар булмаганда, муниципаль торак инспекторы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яки таләпләрне бозу билгеләрен ачыкласа, муниципаль торак инспекторы күчмә тикшерү үткәрергә хокуклы.

53. Әлеге бүлекчәдә каралган административ процедураны туктату рөхсәт ителми.

54. Әлеге бүлектә каралган административ процедураның нәтиҗәсе булып административ регламентның әлеге бүлекчәсендә каралган барлык чараларны гамәлгә ашыру тора.

55. Башкарма комитетның күчмә тикшерү (планлы, планнан тыш) үткәрү турында Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән боерыгы күчмә тикшерүне башлау өчен нигез булып тора.

56. Әлеге административ регламентның 3 бүлегендәге 36 пункты, 4 пункттагы 4 пунктчаның 2, 3 абзацларында каралган нигезләр буенча юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү, Федераль законда билгеләнгән тәртиптә мондый юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештерелгәннән соң, муниципаль торак контроле комиссиясе үткәрелергә мөмкин.

57. Планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы карар түбәндәге нигезләрнең барлыкка килүе булып тора:

1) муниципаль торак фондына карата федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, шулай ук муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозуны бетерү турында муниципаль контроль органы тарафыннан бирелгән күрсәтмәнең үтәлү срогы тәмамлануы;

2) гражданнарның, шул исәптән шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан түбәндәге фактлар турында мәгълүмат керүе;

а) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), дәүләт иминлегенә зыян китерү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

б) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләргә), дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү;

в) кулланучылар хокукларын бозу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта).

58. Муниципаль контроль органына мөрәҗәгать иткән затны билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге административ регламентның 57 пунктында күрсәтелгән фактлар турында белешмәләр булмаган мөрәҗәгатьләр планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

59. Муниципаль контроль органы дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары белән уртак тикшерүләр үткәрә ала.

60. Муниципаль контроль органы, мондый зарурлыкның нигезле булуын күрсәтеп, уртак тикшерү үткәрү турында тәкъдим белән прокуратура органнарына, хокук саклау һәм башка контрольлек итүче (күзәтчелек) органнарга мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән органнар вәкилләре тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затлар составына, тикшерүдә катнашу өчен тәкъдим ителә торган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын күрсәтеп, рәсми хатлар нигезендә кертелә.

61. Күчмә тикшерүнең (планлы, планнан тыш) предметы булып түбәндәгеләр тора:

- юридик зат, шәхси эшмәкәр документларындагы мәгълүматларны тикшерү;

- алдан ук наемга алучылар һәм арендаторлар белән килештерелгән вакытта күпфатирлы йортлар, күпфатирлы йортларның гомуми файдаланудагы урыннары, күпфатирлы йортларда муниципаль торак фондының торак урыннары территорияләрен тикшерү, шулай ук тикшеренү, сынау, экспертиза һәм контроль буенча башка чаралар;

- Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясындагы 2 өлештә каралган йөкләмәләрне идарәче оешмалар тарафыннан бозу очракларын тикшерү;

- юридик затның, шәхси эшмәкәрнең муниципаль торак фондына карата федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерү.

- гражданнар тарафыннан торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, шулай ук муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү, муниципаль контроль органы күрсәтмәләрен үтәү, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүне булдырмау, дәүләт иминлеген тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, мондый зыян китерү нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар үткәрү.

62. Күчмә тикшерү (планлы, планнан тыш) юридик затның эшчәнлек алып бару урыны, шәхси эшмәкәр һәм (яки) аларның эшчәнлеген фактта гамәлгә ашыру урыны буенча үткәрелә.

63. Күчмә тикшерү (планлы, планнан тыш) җитәкчене яки юридик затның башка вазыйфаи затын, шәхси эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен күчмә тикшерүне

үткәрү (планлы, планнан тыш) турында Башкарма комитетның боерыгы һәм күчмә тикшерү үткәрүче затларның вәкаләтләре белән, шулай ук күчмә тикшерүне үткәрү максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольдә тоту чараларының төрләре һәм күләме, экспертларның составы, күчмә тикшерүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмалары вәкилләре, аны үткәрү вакыты һәм шартлары белән мәҗбүри таныштырудан башлана.

64. Тикшерү тикшерелә торган затның гамәлләре (гамәл кылмавы) муниципаль торак фондына карата федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәүгә бәя бирү максатларында үткәрелә.

65. Муниципаль контроль органы вазыйфаи затларының күчмә тикшерү үткәрүче территориягә яисә тикшерелә торган зат урынына керүгә комачаулаган очракта, муниципаль контроль органы вазыйфаи заты тикшерү үткәрүгә комачаулаучы затларны административ хокук бозу турында кисәтә.

66. Муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан, тикшерелә торган затның бинага керүенә комачаулау факты буенча, әлеге административ регламентка 2 нче кушымта нигезендә, форма буенча акт төзелә. Акт муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары һәм тикшерелүче зат яки аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалана. Тикшерелә торган зат яки аның вәкаләтле вәкиле әлеге актка кул куюдан баш тарткан очракта, анда тиешле язма ясала.

67. Тикшерү актын төзү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук тикшерелүче затның язма һәм телдән аңлатмаларыннан, шулай ук фотога төшерү, видеоязма куллану юлы белән һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка рәвешләрдә алынырга мөмкин.

68. Күчмә тикшерү үткәрүче муниципаль контроль органы вазыйфаи затлары тикшерелә торган заттан тикшерелә торган затка, аның вәкаләтле вәкиленә әлеге административ регламентка 3 нче кушымта нигезендә документлар һәм мәгълүмат бирү турында дәлилләнгән запрос (таләпләр) тапшыру юлы белән тикшерү уздыру өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны таләп итәргә хокуклы. Мондый таләп тикшерелүче затка, аның вәкаләтле вәкиленә имза кую өчен тапшырыла яки заказлы почта аша, тапшыру турында белдерү кәгазе җибәрелә.

69. Таләп ителә торган документлар һәм мәгълүмат тикшерелә торган зат тарафыннан күрсәтелгән таләпне (таләпләрне) алганнан соң өч эш көненнән дә артмаган срокта тапшырыла.

70. Запроста күрсәтелгән документлар мөһерле (булганда) һәм тикшерелә торган затның, аның вәкаләтле вәкиленең имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла.

71. Тикшерелә торган затның таләбе буенча соратып алына торган документларны тапшыру документларны кабул итү-тапшыру акты нигезендә башкарылырга мөмкин.

72. Әгәр тикшерелә торган зат кирәкле документларны (аларның күчермәләрен) һәм мәгълүматны өч эш көне эчендә тапшыра алмаса, тикшерелә торган зат күчмә тикшерүне үткәрүгә вәкаләтле муниципаль контроль органы вазыйфаи затларына, билгеләнгән срокта тапшырылырга мөмкин булмаган сәбәпләрен һәм срокларын күрсәтеп, документларны һәм мәгълүматны язма рәвештә

тапшыру мөмкинлеге булмау турында муниципаль контроль органы вазыйфаи затларына хәбәр итә.

73. Мондый белдерү кәгазен алган көннән соң ике эш көне эчендә күчмә тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар документлар һәм мәгълүмат тапшыруның яңа срогын билгеләү турында дәлилләнгән карар кабул итәләр яисә баш тартуның нигезләнүен күрсәтеп, срокны озайтудан баш тарту турында дәлилләнгән карар кабул итәләр. Кабул ителгән карарның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе тикшерелә торган затка теләсә нинди мөмкин булган ысул белән җибәрелә.

74. Әгәр документлар һәм мәгълүмат тапшыру турындагы таләп билгеләнгән срокта үтәлмәсә, муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан гаепле затка карата гамәлдәге законнар нигезендә чаралар күрү турындагы мәсьәлә хәл ителә.

75. Җитәкче (җитәкче урынбасары) һәм муниципаль контроль органы вазыйфаи затларыннан тикшерелә торган затның вазыйфаи затларыннан кирәкле язма аңлатмалар, тикшерү барышында барлыкка килгән мәсьәләләр буенча белешмәләр алырга хокуклы, шул исәптән тикшерү үткәрү өчен кирәкле документлар булмау факты буенча да. Күрсәтелгән аңлатмаларны бирүдән баш тарткан очракта, тикшерү актында тиешле язма ясала.

76. Әлеге бүлекчәдә каралган административ процедураны туктату рөхсәт ителми.

77. Әлеге бүлектә каралган административ процедураның нәтиҗәсе булып административ регламентның әлеге бүлекчәсендә каралган барлык чараларны гамәлгә ашыру тора.

78. Тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү өчен нигез булып документар яки күчмә тикшерүне тәмамлау факты тора. Тикшерү акты тикшерү үткәрүче комиссия тарафыннан төзелә. Тикшерү актын төзегәндә комиссия Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында «Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең муниципаль контроле органы, муниципаль контроль органы тарафыннан тикшерү актының типлаштырылган рәвешенә таяна.

79. Тикшерү актында күрсәтелә:

1) тикшерү актын төзү датасы, вакыты һәм урыны;

2) муниципаль контроль органы исеме;

3) тикшерү үткәрү турында Башкарма комитет боерыгының датасы һәм номеры;

4) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яисә вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы;

5) тикшерелә торган затның, аның тикшерү уздырганда катнашкан вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

6) тикшерү үткәрү датасы, вакыты, дәвамлылыгы һәм урыны;

7) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм таләпләрне бозу очраклары турында, аларның характеры һәм әлеге кимчелекләргә юл куйган затлар турында мәгълүматлар;

8) тикшерү үткәргәндә фотога төшерү, аудио-, видеоязма куллану турында мәгълүматлар (алар кулланылганда);

9) тикшерелә торган затны, аның тикшерү үткәргәндә катнашкан вәкаләтле вәкилен тикшерү акты белән таныштыру яки танышудан баш тарту турында, аларның имзалары булу турында яки имза куюдан баш тарту турында мәгълүматлар;

10) тикшерү үткәргән вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның имзалары.

80. Тикшерү акты кәгазьдә ике нөсхәдә төзелә, шуларның берсе кушымталарның күчермәләре белән җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә танышу турында расписка белән тапшырыла. Тикшерү акты белән танышудан баш тарткан очракта, актның икенче нөсхәсендә тиешле билге ясала.

81. Җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышудан яки танышудан баш тартуыннан баш тарткан очракта, комиссия тикшерү актын заказлы почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе белән җибәрә, ул комиссия эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

82. Тикшерү актына продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын сайлап алу беркетмәләре, үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар һәм экспертизалар беркетмәләре яки бәяләмәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яисә таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр хезмәткәрләренең аңлатмалары, ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмәләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре теркәлә.

83. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү өчен аны прокуратура органы белән килештерү таләп ителсә, тикшерү үткәргән комиссия тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына, тикшерү акты төзелгәннән соң 5 (биш) эш көне эчендә тикшерү актының күчермәсен теркәп, аңлатма хаты җибәрә.

84. Дәүләт, коммерция, хезмәт, башка серләр булган мәгълүматлы тикшерү нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнарында каралган таләпләрне үтәп рәсмиләштерелә.

85. Комиссия юридик затны, шәхси эшмәкәрне тикшерүне исәпкә алу журналында (мондый журнал булганда) үткәрелгән тикшерү турында, тикшерүне башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләр, тикшерү максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган кимчелекләр һәм бирелгән күрсәтмәләр, шулай ук тикшерү үткәрә торган муниципаль контроль затларының фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм аларның вазыйфаларын үз эченә алган язма яза. Тикшерүләрне исәпкә алу журналы булмаганда, тиешле язма тикшерү актында ясала.

86. Тикшерү акты тикшерүне үткәрүче комиссия тарафыннан тикшерү тәмамланган көнне төзелә.

Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булса, тикшерү акты төзү контроль буенча чаралар тәмамланганнан соң 3 (өч) эш көненнән дә артмаган срокта төзелә.

87. Әлеге бүлекчәдә каралган административ процедураны туктату рөхсәт ителми.

88. Әлеге бүлекчәдә каралган административ процедураның нәтиҗәсе булып юридик затка, шәхси эшмәкәргә, шулай ук прокуратура органнарына (әлеге административ регламентның 81 пунктында билгеләнгән очракларда) тикшерү акты һәм теркәп бирелә торган документларны тапшыру (җибәрү) тора.

89. Тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмәләр бирү өчен нигез булып юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуын документар яки күчмә тикшерү уздырганда ачыклау факты тора.

90. Тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә әлеге административ регламентка 5 нче кушымта нигезендә тикшерү үткәргән комиссия тарафыннан төзелә.

91. Күрсәтмә кәгазьдә ике нөсхәдә төзелә, аларның берсе җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яки юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән бергә расписка белән тапшырыла.

92. Күрсәтелгән тәртиптә күрсәтмәне тапшыру мөмкин булмаса, күрсәтмә заказлы почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе белән җибәрелә, ул комиссиядә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

93. Тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә юридик затка, шәхси эшмәкәргә тикшерү акты төзү һәм тапшыру (җибәрү) көнендә төзелә һәм тапшырыла. Әлеге административ регламентның 92 пунктында билгеләнгән очракларда, тикшерү актын тиешле юридик затка, шәхси эшмәкәргә тапшырган (җибәргән) вакыттан соң 3 (өч) эш көненнән дә артмаска тиеш.

94. Тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләргә юл куйган юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне җаваплылыкка тарту максатыннан, тикшерү материалларын тикшерү өчен нигез булып, административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләрен документар яки күчмә тикшерү уздырганда ачыкланган факт тора.

95. Тикшерү материалларын компетентлы органнарга яки вазыйфаи затларга җаваплылыкка тарту максатында тапшыру турындагы мәсьәлә тикшерү үткәргән комиссия тарафыннан кертелгән тәкъдимнәр нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карап тикшерелә.

96. Тикшерү үткәргән комиссия тәкъдимнәре, тикшерү акты төзелгән көннән соң килүче 2 (ике) эш көненнән дә артмаган срокта кәгазьдә рәсмиләштерелә. Рәсми язуда административ хокук бозу яки җинаять билгеләре, документар яки күчмә тикшерү үткәргәндә ачыкланган конкрет хәлләр турында мәгълүматлар булырга тиеш. Рәсми язу комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

97. Тикшерү материалларын компетентлы органнарга яки вазыйфаи затларга тапшыру турындагы карар, кимчелекләргә юл куйган затларны җаваплылыкка тарту максатларында, Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан карар кабул ителә һәм ул тиешле рәсми язуда резолюция рәвешендә рәсмиләштерелә. Мондый резолюция белән рәсми язу комиссиядә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.

98. Тикшерү материалларын компетентлы органнарга яисә вазыйфаи затларга кимчелекләргә юл куйган затларны җаваплылыкка тарту максатларында тапшыру турындагы мәсьәлә комиссия тарафыннан рөхсәт ителергә тиешле вакыт тикшерү актын төзегән көннең соңгы 5 (биш) эш көненнән артмаска тиеш.

99. Тикшерү материалларын компетентлы органнарга яки вазыйфаи затларга тапшыру мондый материалларны тапшыру турында карар кабул ителгән көннән соң килүче бер эш көненнән дә артмаган срокта гамәлгә ашырыла. Мондый материаллар составында тикшерү актының һәм тикшерү үткәргәндә комиссия тарафыннан төзелгән һәм (яки) алынган башка документларның тиешенчә расланган күчермәләре тапшырыла.

100. Тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшерү өчен нигез булып юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бетерү турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең үтәлү вакыты чыгу тора.

101. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшерү һәм аның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата әлеге административ регламентның 3 бүлегенең 3.3-3.7 бүлекчәләрендә каралган кагыйдәләр кулланыла.

## Бүлек 4. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны тикшереп тору тәртибе һәм формалары

102. Контроль чараларында катнашучы вазыйфаи затлар күрсәтмәләрнең үтәлешен контрольдә тоталар, муниципаль контроль барышында вазыйфаи затларның үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәү очракларын исәпкә алып баралар, тиешле тикшерүләр уздыралар һәм мондый вазыйфаи затларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чаралар күрәләр.

103. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

104. Үткәрелгән контроль чаралар нәтиҗәләре буенча, муниципаль функцияне үтәгәндә вазыйфаи затлар тарафыннан җибәрелгән кимчелекләр ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла. Шул ук вакытта ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрелә.

105. Муниципаль функцияне үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затлар муниципаль функцияне үтәү барышында алар тарафыннан кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен җаваплы.

## 5. бүлек. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыра торган органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

106. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, физик зат яки аның вәкиле, башка кызыксынган затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затлары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә тикшерү вакытында юридик затның, шәхси эшмәкәрнең, гражданның хокуклары бозылуга юл куелса, муниципаль торак контроле органы, аның

вазыйфаи затларының муниципаль функцияләрен үтәү барышында эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү хокукына ия.

107. Муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затларының судка кадәр (судтан тыш) эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирү предметы булып муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының муниципаль функцияләрне үтәү барышында кабул иткән яки гамәлгә ашырган карарлары яки эш итүләре (эш итмәүләре) тора.

108. Муниципаль торак контроле органына яки вазыйфаи затка кергән шикаять аларның компетенциясе чикләрендә мәҗбүри рәвештә карап тикшерелергә тиеш. Шикаятьне судка кадәр (судтан тыш) карап тикшерүне яки туктатуны кире кагу өчен сәбәпләр булырга тиеш түгел.

109. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми:

1) әгәр язмача шикаятьтә шикаять җибәрүченең фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәгән булса (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә хокук бозу юлы белән әзерләнә, башкарыла яки башкарылган эшләр турында, шулай ук аны әзерләгән, башкара торган яки башкарган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять үз компетенциясе чикләрендә дәүләт органына юлланырга тиеш);

2) әгәр шикаятьтә цензуралы булмаган яки кимсетүле сүзләр, муниципаль торак контроле органының вазыйфаи заты тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә, шулай ук аның гаилә әгъзаларына куркыныч янау булса (муниципаль торак контроле органының вазыйфаи заты шикаять итүчегә хокукыннан явыз ниаттә файдалану ярамаганлыгын хәбәр итәргә хокуклы);

3) әгәр язмача шикаять тексты укырлык булмаса (күрсәтелгән шикаять шулай ук карап тикшерү өчен компетенция чикләрендә дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш түгел), бу хакта шикаять теркәлгәннән башлап җиде көн эчендә шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе (юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе), почта адресы укырлык дәрәҗәдә булса;

4) әгәр гариза бирүченең шикаятендә аның элек җибәрелгән шикаятьләренә берничә тапкыр нигезле җаваплар бирелгәннән соң да шикаятьнең составында яңа хәбәрләр яки хәлләр китерелмәгән сорау булса (әлеге шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки бер үк вазыйфаи затка юлланган булса), (шикаять җибәрүчегә язышуны туктату карары турында хәбәр ителә);

5) әгәр шикаятьтә куелган нигезле сорау буенча җавап дәүләт яки башка федераль закон белән саклана торган сер булган мәгълүматларны таратмыйча бирелә алмаса (шикаять җибәрүчегә анда куелган сорауга әлеге мәгълүматларны тарату ярамау сәбәпле, нигезле җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә).

110. Муниципаль торак контроле органы, аның вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып шикаять бирүчедән (шикаять бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән почта аша юллау, Интернет челтәрендәге мәгълүмати-телекоммуникацияләрне кулланып электрон документ рәвешендә, шулай ук муниципаль торак контроле органының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша шикаятьләр керү тора.

111. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар шикаятьләрне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүмат һәм документларны алырга хокуклы. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, гражданнар, мондый төрдәге мәгълүмат һәм документларны алу өчен, муниципаль торак контроле органына тиешле запросларын язмача рәвештә җибәрергә тиешләр. Җитәкче, җаваплы башкаручылар соралган мәгълүмат һәм документларны запрос теркәлгән көннән башлап утыз календарь көн эчендә бирергә тиешләр.

112. Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының эш итүенә (эш итмәвенә) шикаять муниципаль торак контроле органы җитәкчесенә җибәрелергә мөмкин. Муниципаль торак контроле органының эш итүенә (эш итмәвенә), карарына булган шикаять Башкарма комитетка җибәрелергә мөмкин.

113. Муниципаль торак контроле органына яки муниципаль торак контроле органының вазыйфаи затына аларның компетенцияләре чикләрендә кергән шикаять, ул теркәлгән көннән башлап 15 календарь көн эчендә карап тикшерелә.

Җирле үзидарә органы яки вазыйфаи зат шикаятьләрне карап тикшерә торган җирле үзидарә органы яки вазыйфаи затның билгеләнгән тәртиптә җибәрелгән запросына биш эш көне эчендә шикаятьне карап тикшерү өчен кирәкле документлар һәм материалларны бирергә тиеш, дәүләт яки башка федераль закон белән саклanучы сер булган һәм аларны аерым бирү тәртибе каралган мәгълүматлардан кала.

Искәрмә очракларда, шулай ук әлеге пунктта күрсәтелгән запросны җибәргән очракта, шуңа вәкаләтле булган зат шикаять карауны өч эш көненнән артмаган срокка озайтырга хокуклы, срок озайтылу турындагы хәбәрне шикаять белән мөрәҗәгать итүчегә җиткереп.

114. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять итү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр санала:

1) муниципаль функцияләрне үтәү барышында эш итүгә (эш итмәүгә) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларга карата судка кадәр (судтан тыш) шикаятьләрне канәгатьләндерү, ягъни:

фактларны тикшерү барышында җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәүләре ачыкланган очракта, аларга карата Россия Федерациясе законнары нигезендә чара күрү;

хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуда гаепле җаваплы башкаручыларга карата күрелгән чаралар турында шундый чаралар күрелгән көннән башлап 10 көн эчендә язмача хәбәр итү;

2) муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда эш итү (эш итмәү) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарларны судка кадәр (судтан соң) юридик затка, шәхси эшмәкәргә, гражданга, физик затка, әлеге карарның дәлилләнгән нигезле булуын язмача хәбәр итү юлы белән, шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру.

Муниципаль торак контроле органына яки вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән шикаятькә җавап шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә яки шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә.

115. Муниципаль торак контроле органы шикаятьне карап тикшерү өчен

шикаять итүчедән муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының нигезсез эш итүен раслаучы беренчел документларны электрон рәвештә соратып алырга хокуклы.

Соратып алынган материаллар мөрәҗәгать итүче тарафыннан запрос кергәннән башлап өч эш көне эчендә бирелергә тиеш.

116. Муниципаль торак контроле органы вазыйфаи затларының эш итүләре (эш итмәүләре) нәтиҗәсендә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга китерелгән зыян Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә, урынсыз дип табылса, Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль бюджет акчалары хисабына кире кайтарылырга тиеш, килми калган файданы (алынмаган табышны) да кертеп.

117. Шикаятьне карау нәтиҗәләре федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә судта шикаять ителергә мөмкин.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Административ регламентка
1 нче кушымта

Муниципаль контроль органы бланкында
«___» ____________________ел №
Яр Чаллы шәһәре

Тикшерү (планнан тыш күчмә)
үткәрү турында
БОЕРЫК (1)

1. Тикшерү үткәрергә ____________________________________
(гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
2. Урнашу урыны: ____________________________ ____________
(тикшерелә торган гражданның)
3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле зат (лар) итеп билгеләргә: ________________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)
4. Тикшерү үткәрүгә экспертлар, эксперт оешмалар вәкилләре сыйфатында түбәндәге затларны җәлеп итәргә:
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________
(тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән экспертларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм (яки) эксперт оешмасының исеме)

5. Әлеге тикшерүнең максатын билгеләргә:
__________________________________________________________________

Үткәрелә торган тикшерүнең максатларын билгеләгәндә түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:
а) планнан тыш күчмә тикшерү үткәрелгән очракта:
- ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында алдан бирелгән, аны үтәү вакыты чыккан күрсәтмәнең реквизитлары;
- муниципаль контроль органнарына гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән кергән мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларның реквизитлары;
б) зыян китерүгә яисә тикшерелә торган таләпләрне бозуга бәйле кичекмәстән чаралар күрү максатларында кичекмәстән үткәрелергә тиешле планнан тыш тикшерү уздырылган очракта, әгәр мондый зыян китерү яисә таләпләрне бозу аны кылган вакытта турыдан-туры ачыкланса, кичекмәстән башкарылырга тиешле:
- кимчелекләрне ачыклаган вазыйфаи зат тарафыннан бирелгән документларның (доклад язуының һ. б.) кушып бирелә торган күчермәләре реквизитлары;
- кулланучылар хокукларын бозу очрагында (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгате булганда).

Әлеге тикшерүнең бурычлары булып тора:
6. Әлеге тикшерүнең предметы булып тора (кирәген сызарга):
- муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне яки таләпләрне үтәү;

- муниципаль контроль органы күрсәтмәләрен үтәү. Чаралар үткәрү:
- гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүне булдырмау буенча;
- техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча;
- мондый зыян китерүнең нәтиҗәләрен бетерү буенча.

7. Тикшерү үткәрү вакыты: ____________________________________

Тикшерү үткәрүгә керешергә «___» ___________ 20 ___ ел

Тикшерүне соңрак тәмамларга «___» ______________ 20 ____ ел

8. Тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре: __________________________________

(норматив хокукый актның нигезләмәсенә сылтама, алар нигезендә тикшерү гамәлгә ашырыла; нигезләмәләргә (норматив) хокукый актларга сылтама, тикшерү предметы булып торган таләпләрне билгели)

9. Тикшерү барышында максатларга ирешү өчен кирәкле контроль буенча түбәндәге чаралар үткәрергә: ______________________________________________

тикшерү үткәрү бурычлары: ___________________________________________

10. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар исемлеге (булганда): ______________________________________________________

(атамалары, номерлары һәм аларны кабул итү даталары күрсәтелгән)

11. Тикшерә торган затка тикшерү үткәрүнең максатына һәм бурычларына ирешү өчен бирелергә тиешле документлар исемлеге:_________________________________

(тикшерү үткәрү турында боерык чыгарган контроль органын җитәкчесенең вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары

(муниципаль орган җитәкчесе урынбасары)

__________________________________________

(мөһер белән расланган имза)

(1) Әлеге административ регламентка 1 нче кушымта Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган типлаштырылган форма нигезендә әзерләнде.

Административ регламентка
2 нче кушымта

Муниципаль контроль органы бланкында

«____» ______________________ ел N _____

Яр Чаллы шәһәре

Вазыйфаи зат тикшерелә торган затның
территориясенә (бинага) керүенә комачаулау турында
АКТ

Тикшерү үткәргәндә: ___________________________________________________________________________________________________________________,

(тикшерүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны адресы)
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда гражданнарны, муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи зат тарафыннан тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентта билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрү турында хәбәр ителгән:

______________________________________________________________________________

(тикшерү үткәрә торган затларның Ф.И.А и. аларның вазыйфалары)
боерык нигезендә тикшерү үткәрү хокукына вәкаләтле вәкил «____»_____________20__ ел. ______________________ тикшерелә торган затның территориягә (бинага) керүенә тоткарлык булган.
адрес:
________________________________________________________________________________.
(өстәмә мәгълүмат күрсәтелә)

Тикшерү үткәрә торган вазыйфаи затлар:

___________________________ ______________________________________

(вазыйфаи затның Ф.И.А и.) имза, дата_____________

___________________________

вазыйфаи затның Ф.И.А и. имза, дата______________

Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

______________________________________________________________________________________________,

______________________________________________________________________________________________

Административ регламентка
3 нче кушымта

Муниципаль контроль органы бланкында

Тикшерелә торган затның Ф.И.А и.,
яшәү урыны адресы

Документлар (мәгълүмат)тапшыру турында
ЗАПРОС

______________________________________________________________сәбәпле,
Запрос җибәрүнең нигезе күрсәтелә: мөрәҗәгать керү, күрсәтмәне үтәү өчен вакыт узу, торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләрен дәлилләүче материалларны ачыклау

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, 5 өлеше, 1 пункты нигезендә һәм боерык нигезендә (муниципаль контроль органы исемен күрсәтергә)
«___» ______________ 20 ___ ел № ____
тикшерү үткәрү турында

(Тикшерелә торган затның Ф.И.А и.) ______________________________
тапшырырга тиеш:
1.
2.
3.
(соратып алына торган документлар, мәгълүмат санала)
Тапшыру вакыты _______________ 20___ соңрак түгел
Тикшерелә торган затның тикшерү үткәргәндә соратып алына торган документларны һәм мәгълүматны тапшырудан баш тартуы яисә аларны билгеләнгән срокта тапшырмау Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык китерә.
Кушымта: тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе.

Муниципаль контроль органы җитәкче (җитәкче урынбасары)
____________________________________.
Вазыйфаи затлар _________________________________________________.
Әлеге запросны алды _____________ 20___ ел
Ф.И.А и. / (имза)
(Тикшерелә торган затның, аның вәкаләтле вәкиленең Ф.И.А и.);
(ышаныч язуының номеры һәм датасы мәҗбүри күрсәтелә)

Административ регламентка
4 нче кушымта

Муниципаль контроль органы бланкында

| | |
|---|---|
| ____________________ | ____________________ |
| (актны төзү датасы) | (актны төзү урыны) |

______________________________

(актны төзү датасы)

Муниципаль контроль органы тарафыннан гражданны

ТИКШЕРҮ АКТЫ (1) № ____

адрес ________________________________________________________________

(тикшерү үткәрү урыны)

нигез: ________________________________________________________________

(реквизитлары күрсәтелгән документның төре (номеры, датасы), тикшерү үткәрү турында боерык чыгарган муниципаль контроль органы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

карата тикшерү үткәрелде: ____________________________________________

(тикшерелә торган гражданның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда)

тикшерүнең дәвамлылыгы: ____________________________________________

Акт төзелде: ____________________________________________________________

(муниципаль контроль органы исеме)

Тикшерү үткәрү турындагы боерык белән

таныштым: ____________________________________________

(күчмә тикшерү үткәргәндә тутырыла)

(гражданның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда), имзасы, дата, вакыты)

Тикшерү үткәрүче зат: ____________________________________________

(тикшерү үткәрүче вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) фамилиясе, исеме, атасының исеме; тикшерүдә катнашуга экспертларны, эксперт оешмаларын җәлеп иткән очракта, аларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы һәм/яки эксперт оешмаларының исеме күрсәтелә

Тикшерү үткәргәндә

катнаштылар: ____________________________________________

(тикшерү чаралары үткәргәндә катнашучы гражданның, аның вәкаләтле затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

Тикшерү барышында:

муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләр яки таләпләрне бозулар ачыкланды:

________________________________________________________________

(кимчелекләрнең характерын, аңа юл куйган затларны күрсәтеп;)

муниципаль контроль органнары күрсәтмәләрен үтәмәү фактлары ачыкланды (бирелгән күрсәтмәләрнең реквизитларын күрсәтеп);

Кимчелекләр

ачыкланмады ____________________________________________

Теркәлгән

документлар: ____________________________________________

Тикшерү үткәргән вазыйфаи затларның имзалары:

Тикшерү акты белән таныштым, барлык кушымталары белән акт күчермәсен алдым:

(гражданның, аның вәкаләтле затының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

« ___ » ________________ 20 ___ ел ____________________

(имза)

Тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында билге:

Тикшерү үткәргән вәкаләтле вазыйфаи затның (вазыйфаи затларның) имзасы

(1) Административ регламентка 4 нче кушымта Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган типлаштырылган

форма нигезендә әзерләнде.

Административ регламентка
5 нче кушымта

Муниципаль контроль органы бланкында

Тикшерелә торган затның Ф.И А.и.,

яшәү урыны адресы

Ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында (мәҗбүри таләпләрне үтәүне
тәэмин итү чаралары үткәрү турында)

КҮРСӘТМӘ

« ___ » ________________ ел ____________________

(төзү датасы) (төзү урыны)

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ:

___________________________________

(Күрсәтмә бирелгән тикшерелә торган затның Ф.И.А и.)

| N т/б | Күрсәтмәнең эчтәлеге | Үтәү срогы | Нигез (норматив хокукый актка сылтама) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |

* Күрсәтмә бирелгән зат әлеге күрсәтмәнең пунктларын үтәү турындагы мәгълүматны күрсәтмәдә билгеләнгән срокта (срокларда) муниципаль торак контроле органы адресына җибәрергә тиеш.

______________________ ____________ ______________________

(вазыйфаи затның исеме) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________ ____________ ______________________

(вазыйфаи затның исеме) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

М.У.

Күрсәтмә алынды:

______________________

(тикшерелә торган затның яки аның вәкаләтле затының Ф И.А и. (ышаныч язуының номерын һәм датасын күрсәтү мәҗбүри)

______________

(имза)

Дата

Административ регламентка
5 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак
контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең

# БЛОК-СХЕМАСЫ

